ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.02.2021 г. Заинск № 101

**"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актларны эшләү һәм кабул итүгә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында" 2018 елның 28 маендагы 865 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, “Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы 4 өлешенең 1 пунктына таянып, “Сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә гомуми таләпләрне раслау хакында” 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актларны эшләү һәм кабул итү, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында" 2018 елның 28 маендагы 865 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм

аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләрне раслау турында" карарга 1 кушымтаны яңа редакциядә расларга.
2. Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Юрист

Е.А. Улитина 3 79 17

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның ___ ______
___ номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү тәртибенә**
**ТАЛӘПЛӘР**

1. "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында” 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, "Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актларны эшләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата гомуми таләпләрне раслау турында" 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә эшләнгән әлеге документ (алга таба – 476 номерлы карар), хокукый актларны эшләү һәм кабул итү тәртибенә, эчтәлегенә, үтәүне тәэмин итүгә карата таләпләрне (алга таба - таләпләр) билгели:

а) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана торган:

сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, күрсәтелгән актларны карап тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә карата таләпләр;

муниципаль органнар һәм күрсәтелгән органнарга караган казна учреждениеләре, бюджет учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы унитар предприятиеләре тарафыннан товарларның аерым төрләренә, эшләренә, хезмәт күрсәтүләргә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) карата таләпләрне билгеләү кагыйдәләре;

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль органнары функцияләрен (ведомство карамагындагы казна учреждениеләрен дә кертеп) тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре;

б) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль органнары раслый торган:

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль органнары (шул исәптән ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләре) функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

алар сатып ала торган һәм күрсәтелгән органнар буйсынуындагы казна учреждениеләре, бюджет учреждениеләре һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының унитар предприятиеләре тарафыннан аерым товарлар,

эшләр, хезмәтләр (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре) төрләренә карата таләпләр.

2. Әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актлар Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары проектлары рәвешендә эшләнә.

3. Муниципаль органнар әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче абзацында һәм «б» пунктчасының өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын муниципаль органнар каршындагы иҗтимагый советлар утырышларында (алга таба - иҗтимагый советлар) алдан тикшерергә хокуклы.

4. Заказчылар сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә карата таләпләрне билгеләүнең гомуми кагыйдәләре (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең чик бәяләре) үз эченә алырга тиеш:

а) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләре исемлеген (алга таба - исемлек) төзү һәм раслау тәртибен, аларны куллану үзлекләренә (шул исәптән сыйфат характеристикаларына) һәм башка характеристикаларга (шул исәптән иң чик бәяләрне) таләпләрне билгели торган муниципаль органнар түбәндәгеләрне билгели:

исемлеккә кертелә торган мәгълүмат составын;

исемлекне төзегәндә икътисадый эшчәнлек төрләре буенча гомумроссия продукция классификаторын куллану тәртибен;

сатып алучылар үзгәлеген (шул исәптән сыйфат характеристикалары) һәм сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең норматив күрсәткечләрен билгеләү таләп ителә торган башка характеристикаларны сайлау тәртибен;

сатып алучы үзгәлекләрен характерлаучы күрсәткечләргә (шул исәптән сыйфат характеристикаларын) һәм сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең башка характеристикаларын (шул исәптән иң чик бәяләрне) билгеләүгә карата таләпләрне;

исемлеккә кертү өчен товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен сайлап алганда кулланыла торган критерийларны;

б) исемлекнең якынча формасын үз эченә алырга.

5. Муниципаль органнар (казна учреждениеләренә караганнарны да кертеп) функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләүнең гомуми кагыйдәләре түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

а) товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алуга бәйле чыгымнарны классификацияләүне;

б) муниципаль органнар функцияләрен тәэмин итүгә чыгымнарны исәпләү тәртибен билгеләү шартларын (шул исәптән ведомство буйсынуындагы казна учреждениеләрен дә кертеп);

в) күрсәтелгән органнарның һәм учреждениеләрнең төп хезмәткәрләре саны күрсәткечен билгеләү тәртибен.

6. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән хокукый актлары әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «а» пунктчасының өченче һәм дүртенче абзацларында һәм «в» пунктчасының икенче

һәм өченче абзацларында күрсәтелгән актларны әзерләү һәм кабул итү тәртибенә карата таләпләрне, күрсәтелгән актларны тотуга һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә таләпләрне, шул исәптән түбәндәгеләрне билгели:

а) күрсәтелгән актларны хокукый рәвешкә, килештерү тәртибенә һәм сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында раслау һәм урнаштыру срокларына карата таләпләрне;

б) күрсәтелгән актларга үзгәрешләр кертү очракларын;

в) җәмәгать контролен гамәлгә ашыру максатларында күрсәтелгән актлар буенча мәҗбүри фикер алышу таләбен, шулай ук мондый фикер алышу тәртибен.

7. Дәүләт (муниципаль) финанс контроле, сатып алулар өлкәсендә контроль һәм мониторинг үткәрүне җайга салучы законнар һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә, сатып алулар өлкәсендә контроль һәм мониторинг барышында заказчылар тарафыннан әлеге таләпләрнең 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән хокукый актларның үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.